ГАЗЕТА МБОУ «Арская СОШ№2» г. АРСК РТ

Февраль 2017 год

# Пульс школы



**Учение — это лишь один из лепестков того цветка, который называется воспитанием.**

**М. Сухомлинский**




Международный день родного языка, провозглашенный Генеральной конференцией ЮНЕСКО в ноябре 1999 года, отмечается каждый год с февраля 2000 года для содействия языковому и культурному разнообразию и многоязычию.
Языки являются самым сильным инструментом сохранения и развития нашего материального и духовного наследия.
Вот что говорит об этом празднике генеральный директор ЮНЕСКО Коитиро Мацуура: «Отмечая Международный день родного языка... мы отдаем дань уважения несметному числу существующих в мире языков, культурам, которые они отражают, тому творческому заряду, который придают людям их развитие и формы выражения. В Международный день родного языка все языки признаются равными, поскольку каждый из них уникальным образом отвечает предназначению человека и каждый представляет живое наследие, которое нам следует оберегать». Каждый язык самобытен. Даже притом, что глубоко проникнуть в культуру другого языка очень трудно, знание языков расширяет кругозор и открывает перед нами многообразный мир. Знакомство с людьми, говорящими на других языках, дает возможность узнать о наших различиях, способно рассеять страхи перед миром, порождающие национальную рознь.
Сделать мышление более свободным. Если мы говорим лишь на одном языке, часть нашего мозга развивается меньше, наши творческие способности многое теряют. Существует около 300 слов, которые во всех языках имеют точно такой же смысл: я, ты, мы, кто, что, нет, все, один, два, большой, длинный, маленький, женщина, мужчина, есть, видеть, слышать, солнце, луна и т.п.

**Туган телем – иркә гөлем,**
**Киндер сиңа күңел түрем.**

*21 нче февраль Халыкара Туган тел көне уңаеннан мәктәбебездә күп төрле чаралар үтте.*



Ветеран укытучы, туган тел сакчысы - Зыятов Фәрхәт Гани улы белән очрашу кичәсе булды. Анда 6Б,8Б,8В классы укучылары катнашты. Кичәне татар теле һәм әдәбияты укытучылары Лилия Фатыхова, Эльмира Зәбирова әзерләделәр.

**«Туган телем—татар теле»** - әдәби-музыкаль кичә. 2 нче һәм 3 нче А сыйныфы укучылары катнашында, татар теле һәм әдәбияты укытучылары Ралина Сәлахова һәм Фәнүсә Рәхимҗанова җитәкчелегендә үткәрелде.



4 нче А һәм 4 нче Б сыйныфы укучылары арасында "Газиз туган телем" исемле әдәби викторина үткәрелде.Кичәне татар теле укытучылары Фәнүсә Рәхимҗанова, Гөлнара Мөбәрәкшина үткәрде.



**Туган телне кадерләгәхалык — кадерле булыр!**



7 нче сыйныф укучылары класс житәкчеләре Рәсимә Ибраева, Рәмзилә Хәбирова белән берлектә бөек шагыйребез Муса Җәлилнен туган көне һәм Халыкара Туган тел көне уңаеннан әдәби кичә үткәрделәр.

21 нче февраль Халыкара Туган тел көне уңаеннан 6 Б сыйныфында үткәрелгән “Тамчы- шоу». Укытучылары Г.Р. Насибуллина.



## *Сәламәт тәндә - сәламәт акыл*
## *(безнең интервью)*




10–12 нче февраль көннәрендә Сабада Республикакүләм XIV “Сәламәтлек” Спартакиадасы узды. Бу ярыш спорт белән шөгыльләнүче гаиләләрне бергә җыйнады. Әлеге бәйгедә 21 район катнашты. Арча районыннан Дияровлар гаиләсе уңышлы чыгыш ясап, җиңүче исеменә лаек булды. Әлеге ярышны Татарстан Республикасы яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, “Уңыш” физультура – спорт җәмгыяте үткәрде. Бу гаиләне I дәрәҗә диплом, кубок акчалата премия белән бүләкләделәр.

Сыйныфташыбызның кайтуын көтеп алдык һәм аны сорауларга күмдек. Ул безгә менә нәрсәләр сөйләде:

- Бу көнне безне тантаналы рәвештә каршы алдылар. Башта катнашкан районнарның исемлеген укып чыктылар. Сәгать 11 дә чаңгы ярышы башланды. Ярыш беткәч, нәтиҗә ясап, команданың гомуми баллын билгеләделәр. Безнең район беренче. Иң авыры - дартс ярышы булды. Бу номинациядә без өченче урында идек. Беренче көннең ярышы шуның белән тәмамланды.



Икенче көнне үткәрелгән ярыш нәтиҗәләрен кушып, урыннар билгеләделәр. Без монда да алдыгы урыннарны бүтәннәргә бирмәдек. Саба һәм Буа районы бездән аз гына калышып бара иде. Шуннан катнаш эстафета башланды. Беренче урынга чыкканнарны, иң соңгы итеп катнаштырдылар. Минем өлеш бу эстафетада хоккей клюшкасы белән теннис тубын алып барып капкага кертү иде. Әнинең өлешенә көянтә белән су күтәреп алып барып, эстафетаны әтигә тапшыру иде. Ә әтигә, хәтта, ат җигәргә туры килде. Ат кирләнсә дә, әти бу эшне уңышлы башкарып чыкты. Әлеге эстафетада һәрберебезнең тырышлыгы зур роль уйнады. Шулай җиңеп кайттык без. Мондый ярыш Россия күләмендә дә үткәреләсе. Анысына да ныклап әзерләнергә кирәк булыр.

**- Ә син ничә яшьтә чаңгыга басканыңны хәтерлисеңме?**

**Илназ:** Әти белән әни мәктәптә укыганда йөри башлаган. Сеңлем Алиягә 5 яшь иде. Альмир энем 3 яшендә үк йөреп китте. Үземнең кайчан чаңгыга басканымны төгәл хәтерләмим дә.

**- Ә кайчан чын-чынлап спорт белән “җенләнә” башладың?**

**Илназ:** 4 нче сыйныфта укыганда әтинең балачак дусты Рәис Камалов Арчада чаңгы секциясенә йөрүче балалар белән шөгыльләнә башлады. Шунда башта мине, аннары сеңлемне илттеләр.



**- Илназ, сер булмаса, хыялыңны безнең белән дә уртаклаш әле.**

**Илназ:** 8 нче классны тәмамлап, Ижевск шәһәрендә урнашкан “Биатлон мәктәбе” нә кереп китү турында хыялланам.

**- Әңгәмәгез өчен рәхмәт. Уңышлар сезгә!**

## *23 нче февраль—Ватанны саклаучылар көне*

### Әтием—горурлыгым!

Әтием - гаиләбезнең башлыгы, терәге, кайгыртучан, иң мөхтәрәм кешебез. Безне җил-яңгырдан саклаучы һәм хәвеф-хәтәрдән яклаучы да ул. Ә исеме аның - Илфат.



Ул Арча районының кечкенә генә, ямьле табигатьле Гөберчәк дигән авылында гап-гади һөнәрче гаиләсендә үндүртенче бала булып дөньяга килгән. Вагыйз бабам итек баскан, агач эшенә оста булган. Кирәксә өй салган, кирәксә сарай...

Ә Зөһедә әбием тегү теккән, кәҗә һәм куян мамыгыннан җылы, йомшак шәлләр бәйләгән. Бу гаиләнең җиде баласы кечкенә чакларында ук гүр иясе булган. Исән калган балаларның һәрберсен кош балаларыдай кадерләп, яратып, тормышка әзерләгәндә, гаилә башлыгы үкенечле үлем белән көтмәгәндә дөньядан мәңгелеккә китә. Балаларын ашату өчен баскан итекләрен хуҗаларына тапшырмыйм дип киткән җиреннән кире әйләнеп кайтмый, тугызынчы апрельдәге көчле буранда адаша. Тормыш арбасына ике абыйсы белән бергә җигеләләр алар.Төзелеп бетмәгән йортны җиткерәсе, мунча саласы, малга ризык табасы, утын әзерлисе һәм башка бик күп мәшәкатьләр... Өч малай да өрлектәй таза, чибәр, акыллы булып үсеп җитә. Бер-бер артлы илебез чиген саклап, хәрби бурычларын үтәп кайталар.

Әтием кечкенәдән эшкә өйрәнеп үскәнгәме, әллә әтиәнисе оста һөнәрчеләр булгангамы, бер минут та тик тора алмый. Аның кулыннан килмәгән бер эш тә юк. Ул бабам кебек балта остасы да, сугымчы да, электрик та, эретеп ябыштыручы да, сантехник та. Нәкъ менә минем әти кебекләргә “алтын куллы” диләр дә инде.

Әгәр дә ышынмасагыз, өебезгә килеп карагыз. Өебезне матур итеп баштанаяк үзе төзеде ул. Мунча, капкакойма эшләү, су үткәрү, канализация сузу да бар кешенең кулыннан килә торган эш түгел бит. “Үз кулың белән эшләгән әйбер генә кадерле була ул”,- ди әтием. Аннан күреп, мин дә кул эшләрен яратып башкарам. Энҗедәй бисерләрне тезеп, кулдан ясаган әйберләремне иң башта әтиемә күрсәтәм.

Әтием бер эшне дә кешегә кушып эшләтми. Бар эшне дә үзе эшли. Күрше-тирәләргә һәрвакыт ярдәм итә. Эшкә дә, сүзгә дә, уен-көлкегә дә бик оста ул. Безгә дә күңелсезләнеп утырырга ирек бирми. Мәзәк сөйләп булса да күңелне күтәрә белә.

.. Борһан бабай үлеп киткәч, әниемнең әнисе ялгыз калды. Шул вакытта әти аның өчен дә зур терәк булды. Инде менә ничә еллар әнинең әнисен- Рауза әбиебезне кадер-хөрмәттә яшәтә бит әле ул. 8 ел инде әби безнең белән яши. Әтинең бу кадәр ихтирам күрсәтүенә барлык туганнар, бигрәк тә әби гел рәхмәтле. Әтинең апа белән мине ничек яратканын белсәгез иде сез! Үскән саен, әни белән иңгә-иң куеп тату яшәүләренә чын күңелдән сокланабыз. Алар белән горурланабыз без. Эштән арып кайтканда, янында йөгереп йөрүче кызлары булганга ул да шатланадыр. Минем гел әтиле буласым килә. Минемчә, әти –әниле булу - иң зур

## *Воспитательный процесс в школе*

Прошел месячник гражданско-патриотического воспитания, посвященный Дню защитника Отечества.



**15-17 февраля** отряд юнармейцев АСОШ № 2 принял участие на Республиканском этапе Всероссийской военно—патриотической игры "Победа". Ребята были приглашены на Игру, так как вошли в число призеров военно-спортивной игры "Вперёд, юнармейцы!", осенью 2016 г. В этот раз в Игре " Победа" приняли участие 20 сильнейших команд РТ. Состязания были сложные и конкуренция была сильная, но не смотря на это наши ребята вернулись с победой в одной из этапов Игры: в тактической Игре "Пейнтбол".

НШ ВДЮВПОД "ЮНАРМИЯ" Арского района.

### Биатлон



18 февраля в школе прошли соревнования по биатлону среди обучающихся 5-8 классов. Соревнования были посвящены годовщине вывода войск из Афганистана и памяти воина-интернационалиста, выпускника нашей школы М.Лотфуллина. В мероприятии приняли участие участник войны Афганистане прапорщик запаса Р.Р. Замалиев, представитель Совета отцов школы А.Ханафиев.

### Подготовка к возложению венков



Юнармейцы МБОУ "Арская СОШ№2" провели работу по подготовке могил к Церемонии возложения венков к могилам воинов-афганцев на татарском кладбище г. Арск, приуроченной годовщине вывода войск из Афганистана.

### А ну-ка, мальчики!



25 февраля в спортивном зале школы прошли соревнования "А ну-ка, мальчики!" между 4а и 4б классами. Организовали и провели мероприятие учителя Галиуллина

### Спартакиада работников образования



14 февраля на стадионе г. Арск прошла Спартакиада работников образования по лыжным видам спорта, в котором приняла участие и наша школа. В забеге на 1 км Гиниятуллина Г.И. заняла I место, Набиуллин Р.Р. -I место, в смешанной эстафе команда учителей (Саляхов И.В., Набиуллин Р.Р., Гараева Д.Я., Ахмадуллина М.Р.) - III место.

### А ну-ка, парни!



27 февраля в спортзале нашей школы состоялись соревнования "А ну-ка, парни!" среди юношей 9-11 классов. В соревнованиях приняли участие команды состоявшие из 4 людей (1 командир и 3 участника).

Задачи соревнований: неполная разборка и сборка автомата АК-74, снаряжение магазина АК-74, надевание противогаза, подтягивание, поднятие гири,

перетягивание каната и конкурс на лучший концертный номер, который ставили девушки - болельщицы каждого класса.

### Лыжные соревнования



25 февраля на стадионе г. Арск состоялись лыжные соревнования, посвященные памяти Ф.Гарафиева. Диярова А. (5б класс) заняла I место. Дияров И. (7б класс) занял I место. Саляхова Ф. (11б класс) заняла I место. Учитель физкультуры Набиуллин Р.Р. занял III место. Поздравляем с победами!

### Афганистан—боль моей души

27 февраля в актовом зале школы прошло мероприятие “Афганистан—боль моей души”.

### «Завершение военно—патриотического месячника».



28 февраля в школе состоялась торжественная линейка. Подвели итоги прошедшего месяца.

## Из жизни школы...

### Учитель года - 2017



1 февраля в школе прошел зональный этап конкурса "Учитель года - 2017". В нем приняли участие учителя Арского, Атнинского, Балтасинского, Кукморского и Тюлячинского районов. В этот день учителя показали открытые уроки. Нашу школу представляла Н.Ф. Прыткова.

### Школа будущего первоклассника



4 февраля в школе начались занятия с будущими первокалссниками. В актовом зале для родителей было проведено организационное собрание, на котором выступила директор школы Г.Г Гиниатуллина, педагог-психолог Галеева В.И. Будущие первоклассники познакомились со школой.

### Всероссийский "День сдачи ЕГЭ родителями"



7 февраля на базе нашей школы родители обучающихся 11-х классов Арского муниципального района приняли участие во Всероссийской акции "День сдачи ЕГЭ родителями". Основной задачей проведения акции является ознакомление родителей с процедурой проведения единого государственного экзамена.

### Призер Республиканской олимпиады

Прошел Республиканский этап Всероссийской олимпиады школьников по математике, на котором обучающийся 5а класса Галаутдинов Н. стал призером. Поздравляем Нияза и его учителя по математике Мухаметзянову Г.Я.



### Ул - җиңүче



Татар теле буенча Республика олимпиадасында 9 нчы А сыйныфы укучысы Хадыкина Екатерина Җиңүче булды (Мөбәрәкшина Г.Р.)

**КОТЛЫЙБЫЗ!**

Татар теле буенча республика олимпиадасының йомгаклау этабында мәктәбебезнең 6 А сыйныфы укучысы Никитина Эльзана (укытучысы Нәбиуллина Ф.Х.), призер булды.



## Районный семинар

17 февраля на базе нашей школы прошел практический семинар на тему: "Организация деятельности учителя искусства в условиях реализации ФГОС", на котором учителя А.Ф. Мухаметгалиева и Л.Г. Зиннатуллина дали открытые уроки в 4а классе "Восточный стиль в творчестве русских композиторов" и в 5в классе "Полхов - Майданская матрешка", К.Р. Галиуллина и В.Р. Мухутдинова с обучающимися 4а и 4б классов показали внеклассное мероприятие "Веселые нотки"



### Муса Җәлил исемендәге IV республикакүләм фәнни – гамәли конференция



17 нче февраль көнне Балтач районы Бакый Зыятдинов исемендәге Карадуган гимназиясендә уңышлы чыгыш ясап, Диләрә Гыйбадуллина 10Б кл. (укытучысы Ф.Х.Нәбиуллина) - сертификат; Рүзәл Шәрипов 7Бкл. (укытучысы Р.Х.Ибраева) I дәрәҗә диплом белән бүләкләнде. Уңышлар телибез!

### Безопасность на железной дороге

17 февраля с обучающимися 5-х, 7-х классов работник железной дороги Д.В. Малянов провел профилактическую беседу на тему "Твоя безопасная железная дорога" с показом презентации и видеоролика.

### Спортивная жизнь

4 февраля прошло Первенство Балтасинского района по лыжным гонкам на призы МС СССР Аскарова Ралифа Рафиковича. Среди учащихся 2005-2006 г.р. Диярова Алия (5б класс) заняла I место.





Татар теле укытучылары Ф.Х.Нәбиуллина, Г.Г. Гарипова җитәкчелегендә 6 нгы сыйныфлар арасында, Туган тел көне уңаеннан, "Туган телем- иркә гөлем" темасына КВН үткәрелде.

Напоминаем, что акция **"Свой в вклад в школьный музей"** продолжается. Ждем от вас новых экспонатов.

**Редакторы газеты:**

Р.Б.Хабреева-учитель русского языка и литературы

Р.Х.Ибраева-учитель татарского языка и литератруы

**Редколлегия:** Шарипов Рузаль, Хабирова Алия, Галимова Диана, Шаяхметова Ляйсан, Киямова Адиля